| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 декабрь 2016ел № 7193

Электрон биржа мәйданчыгында товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашырганда вәкаләтле орган һәм заказчының үзара эшчәнлеге тәртибен раслау турында

«Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль законның 26 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Электрон биржа мәйданчыгында товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашырганда вәкаләтле орган һәм заказчының үзара эшчәнлеге тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләренә һәм предприятиеләренә, шулай ук муниципаль берәмлек өлеше 100% тәшкил иткән акционерлык җәмгыятьләренә һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләргә «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль законның 93 маддәсендәге 1 бүлекнең 4, 5 пунктларында каралган товарларны, эшләрне, хезмәтләр сатып алуны bp.zakazrf.ru электрон биржа мәйданчыгында гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2016 елның 30 декабрендәге
7193 нче карарына
кушымта

Электрон биржа мәйданчыгында товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашырганда вәкаләтле орган һәм заказчының үзара эшчәнлеге
тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге bp.zakazrf.ru электрон биржа мәйданчыгында товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашырганда вәкаләтле орган һәм заказчының үзара эшчәнлеге тәртибе (алга таба - тәртип) бердәнбер алып килеп бирүчедән (подрядчыдан, үтәүчедән) «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль законның 93 маддәсендәге 1 бүлекнең 4, 5 пунктларында каралган сатып алуларны үткәрү юлы белән Яр Чаллы шәһәре заказчыларының ихтыяҗлары өчен сатып алуларны формалаштыру һәм гамәлгә ашыру процессында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2. Әлеге тәртиптә түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

1) Заказчы – казна, бюджет, автономияле учреждениеләр, муниципаль унитар, казна предприятиеләре, акционерлык җәмгыятьләре, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр;

2) Вәкаләтле орган – «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ. Вәкаләтле орган функцияләрен Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеге (алга таба – муниципаль заказ бүлеге) гамәлгә ашыра;

3) Электрон биржа мәйданчыгы (алга таба – биржа мәйданчыгы) – заказчылар бердәнбер алып килеп бирүчедән (подрядчыдан, үтәүчедән) «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль законның 93 маддәсендәге 1 бүлекнең 4, 5 пунктларында каралган сатып алуларны гамәлгә ашыра торган «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге сайт (www.bp.zakazrf.ru).

4) Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы – «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль законның 4 маддәсенең 3 бүлегендә күрсәтелгән һәм әлеге мәгълүматны формалаштыруны, эшкәртүне, саклауны, шулай ук аны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге бердәм мәгълүмат системасының рәсми сайтыннан (алга таба – zakupki.gov.ru рәсми сайты) файдаланып бирүне гамәлгә ашыра торган мәгълүматлар, мәгълүмати технологияләр һәм техник чаралар базасындагы мәгълүматлар җыелмасы;

5) Финанс органы – сатып алулар нәтиҗәсе буенча төзү күздә тотыла торган контракт (килешү) йөкләмәләренә түләү өчен кирәкле сатып алуларны финанслау лимитларын раслый торган «Муниципаль учреждениеләрне финанслау үзәге» МБУ;

6) Биржа мәйданчыгы операторы (алга таба – Оператор) – «Татарстан Республикасының дәүләт заказы, инвестиция эшчәнлеге һәм төбәкара элемтәләр агентлыгы» ДУП;

7) Контракт – муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен муниципаль казна учреждениеләре белән төзелә торган килешү;

8) Килешү – бюджет, автономияле учреждениеләр, муниципаль унитар, казна предприятиеләре, акционерлык җәмгыятьләре, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр белән төзелә.

## 2 бүлек. Заказчыларның ихтыяҗлары өчен сатып алуларны формалаштыру һәм гамәлгә ашыру

3. Сатып алу түбәндәге тәртиптә формалаштырыла һәм гамәлгә ашырыла:

1) Булачак (күздә тотылган) сатып алу турындагы мәгълүматларны сатып алуларны гамәлгә ашыру план-графигына кертү;

2) Түбәндәге документларны (алга таба – сатып алуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар) әзерләү һәм кәгазь һәм электрон төрдә формалаштыру:

а) Финанс органы белән килешенгән сатып алуны гамәлгә ашыруга заявка;

б) Техник йокләмә;

в) Контрактның башлангыч (максималь) бәясен нигезләү (кирәк булганда);

г) Контракт (килешү) проекты.

3) Муниципаль заказ бүлеге тарафыннан сатып алуны гамәлгә ашыру өчен заказчы тапшырган документларны тикшерү;

4) Муниципаль заказ бүлеге тарафыннан, биржа мәйданчыгының эш регламентына туры китереп, биржа мәйданчыгында сатып алу турында хәбәр формалаштыру һәм урнаштыру;

5) Гамәлгә ашырылган сатып алу йомгаклары буенча биржа мәйданчыгында муниципаль заказ бүлеге тарафыннан электрон формада контракт (килешү) төзү;

6) Гамәлгә ашырылган сатып алу йомгаклары буенча заказчы тарафыннан алып килеп бирүче (подрядчы, үтәүче) белән кәгазь төрдә контракт (килешү) төзү;

7) Заказчы тарафыннан контрактны (килешүне) үтәү.

## 3 бүлек. Булачак (күздә тотылган) сатып алу турындагы мәгълүматларны сатып алуларны гамәлгә ашыру план-графигына кертү тәртибе

Булачак (күздә тотылган) сатып алу турындагы мәгълүматларны сатып алуларны гамәлгә ашыру план-графигына кертү:

1) Заказчы сатып алуларны сатып алулар план-графигына кертелгән мәгълүматлар нигезендә гамәлгә ашыра. План-графикта каралмаган сатып алулар гамәлгә ашырыла алмый;

2) Бердәнбер алып килеп бирүчедән (подрядчыдан, үтәүчедән) сатып алуны үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла торган сатып алуның план-графигына барлык товарлар, эшләр, хезмәтләр исемлеге кертелергә тиеш;

3) Һәр объект буенча рәсми сайтка урнаштырылган план-графикка үзгәрешләр кертү сатып алуны гамәлгә ашыру турындагы хәбәр биржа мәйданчыгында урнаштырылган көннән соң ун көннән дә соңга калмый гамәлгә ашырыла;

4) әлеге тәртипнең 3 бүлегенең 3 пунктында күрсәтелгән ун көнне санау конкрет заказчының сатып алулар план-графигы рәсми сайтта басылган датадан соң икенче көннән башлана;

5) Сатып алулар план-графигы рәсми сайтта басылганнан соң, сатып алулар план-графигында заказчының сатып алудагы конкрет позиция белән нинди дә булса гамәл, сатып алулар план-графигында сатып алулар турындагы мәгълүматларга үзгәрешләр кертү дип санала. Бу очракта ун көнне санау конкрет заказчының сатып алулар план-графигы рәсми сайтта кабат басылган датадан соң башлана;

6) Сатып алуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле, муниципаль заказ бүлегенә кергән документларны тикшергәннән соң заказчының план-графигына үзгәрешләр кертү зарурлыгы ачыкланган очракта, муниципаль заказ бүлеге, эшләп бетерү өчен, заявканы заказчыга кире кайтара.

## 4 бүлек. Сатып алуны гамәлгә ашыру өчен заказчы тарафыннан документлар әзерләү тәртибе

4. Сатып алуны гамәлгә ашыру өчен заказчы тарафыннан документлар әзерләү түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла:

1) Заказчы, рәсми сайтта сатып алу план-графигы басылганнан соң, кәгазь һәм электрон төрдә заявка, техник йөкләмә, контракт (килешү) проектын, раслаучы документларны (сметалар, калькуляцияләр һәм исәп-хисапларны) теркәп, контрактның (килешүнең) башлангыч (максималь) бәясен нигезләүне әзерли һәм муниципаль заказ бүлегенә җибәрә;

2) әлеге тәртипнең 4 бүлегендәге 4 пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән документларны муниципаль заказ бүлегенә җибәргәнче, заказчы аларны, сатып алуны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча төзү күздә тотылган контракт (килешү) буенча йөкләмәләрне түләү өчен кирәкле сатып алуны финанслау лимитларын раслау өчен, финанс органына җибәрә. Финанс органы, датаны күрсәтеп һәм тиешле билге кую юлы белән сатып алуны финанслау лимитларын раслый, ә лимитлар булмаган очракта, лимитларны раслауны кире кага. Күрсәтелгән билге булмаса, сатып алуны гамәлгә ашыру өчен документлар муниципаль заказ бүлеге тарафыннан кабул ителми.

## 5 бүлек. Биржа мәйданчыгында сатып алу йомгаклары буенча контракт (килешү) төзү һәм аны үтәү

5. Контракт (килешү) яклар тарафыннан биржа мәйданчыгы регламентына туры китереп төзелә һәм үтәлә. Контракт (килешү) сатып алуда җиңүче тарафыннан тәкъдим ителгән бәя буенча төзелә. Контракт (килешү), биржа мәйданчыгында сатып алу йомгаклары басылган вакыттан соң 5 эш көне эчендә, яклар тарафыннан кәгазь төрдә төзелә. Кәгазь төрдәге контракт (килешү) төзелгәннән соң өч эш көне эчендә, заказчы контракт (килешү) төзү турында мәгълүматларны биржа мәйданчыгына кертергә тиеш.

6. Контракт (килешү) бәясе тотрыклы булырга тиеш һәм аны үтәү барышында ул үзгәрә алмый. Кайтарыла торган товарлар (эшләр, хезмәтләр) өчен түләү контрактта (килешүдә) билгеләнгән бәя буенча гамәлгә ашырыла.

7. Контрактны (килешүне) төзегәндә һәм үтәгәндә, якларның килешенүе буенча һәм берьяклы тәртиптә конракт (килешү) шартларын үзгәртү рөхсәт ителми.

8. Контрактны (килешүне) үтәгәндә контракт (килешү) якларын алыштыру рөхсәт ителми.

9. Контрактны (килешүне) өзү якларның килешенүе, суд карары, РФ Гражданнар кодексында каралган нигезләр буенча берьяклы тәртиптә рөхсәт ителә.

10. Контрактка (килешүгә), контрактта (килешүдә) каралган йөкләмә үтәлмәгән яки тиешенчә үтәлмәгән өчен сатучының җаваплылыгы турында мәҗбүри шарт кертелә.

11. Алып килеп бирүче (подрядчы, үтәүче) тарафыннан контрактта (килешүдә) каралган йөкләмәләр төзелмәгән, үтәлмәгән яки тиешенчә үтәлмәгән очракта, заказчы биржа мәйданчыгы Операторыннан контракт (килешү) төзү һәм аны үтәүне тәэмин итүче акчаларны үз счетына күчерүне һәм күрсәтелгән алып килеп бирүчене (подрядчыны, үтәүчене) биржа мәйданчыгында эшләү мөмкинлегеннән мәхрүм итүне таләп итәргә хокуклы.

12. Контрактның (килешүнең) үтәлеше буенча претензияләр булмау турында акт имзаланган көннән соң бер эш көне эчендә, оператор сатып алуда катнашучының акчаларын блокировкалауны туктата.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова